# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БЕРЕЗНЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

30 октябрь, 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Березняк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставы, Березняк авыл җирлеге Советының 2020 елның 28 гыйнварындагы 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендәгавами тыңлаулар үткәрү юлы белән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проектны тикшерүдә катнашу хокукын үтәү максатыннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Березняк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба – Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты) буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссия (алга таба – Комиссия);

2.2. гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны: 16.11.2024 ел, 11.00 сәгатьтә Березняк авылы мәдәният йортында, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Березняк авылы, Ленин ур., 17 й.;

2.3. авторның фамилиясе, исеме, этисенең исеме, туган елы, яшәү урыны адресын күрсәтеп, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итеlә торган адрес – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы, адресы: 422117, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Березняк авылы, Ленин ур., 17 (дүшәмбе – җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 11.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Березняк авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Березняк авыл җирлеге халкына җиткерү максатларында, Березняк авылында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектының демонстрацион материалларының күргәзмә-экспозициясен оештырырга, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Березняк ав., Ленин ур., 17 й. (дүшәмбе – җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты 11.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгакны, шулай ук Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең үзгәртелгән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә;

3.3. 2024 елның 18 ноябренә кадәр Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм Интернет челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (www.kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (www.kukmor.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Р.Ф. Шәрипов

ОГРН 1061675011024
ИНН 1623008514